ЧАРШӘМБЕ
24
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 45 (6767)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Бөтен халык бәйрәме

Ленин һәм Сталин тарафыннан барлыкка китерелгән, тәрбияләнгән, үстерелгән һәм чыныктырылган, Ватаныбызның азатлыгын һәм бәйсезлеген саклауга чакырылган батыр Кызыл Армиябезнең төзелгән көне бездә һәр ел саен бөтен халык бәйрәме булып үткәрелә. Чөнки безнең Кызыл Армиябез илебездәге хезмәт ияләре вәкилләреннән тора һәм ул халык белән аерылмаслык туганлык каны белән берләшкән. Кызыл Армия — совет дәүләте армиясе, халыклар туганлыгы армиясе, халык интересларын саклаучы армия ул.

Героик Кызыл Армиябезнең тарихи датасын — 25 еллыгын—без, немец-фашист оккупантларга каршы алып барыла торган бөек Ватан сугышы шартларында үткәрәбез. Һәм бу көн—аның барлык тарихында аеруча күренекле урын ала. Баһадир Кызыл Армиябез үзенең 25 еллыгын Гитлерның мактанчык армиясен тар-мар итү белән, Сталинград кебек хәлиткеч участокларда аның 300 меңнән артык гаскәрләрен чолгап алып юк итү белән, Курск, Ростов, Ворошиловград, Харьков һ. б. кебек гаять зур шәһәрләрне алу белән, Ленинград блокадасын өзү белән, Украинада, Донбасста уңышлы һөҗүмнәр алып бару белән, — изге совет җирләрен кабахәт гитлерчы шакшыдан әрчү белән билгеләп үтә.

Кызыл Армия каты сугышлар, җитди сыналулар шартларында туды, үсте һәм чыныкты. Ул 1918 нче елда, яшь совет республикасына басып кергән немец империалистларына каршы сугышта барлыкка килде. Кызыл Петроградны басып алырга дип үзенең канлы кулын сузган немец оккупантларына Нарва һәм Псков янында җимергеч отпор бирелү көне — 23 нче февраль — яшь Кызыл Армиябезнең туу көне булып тарихка керде.

Үзенең туган көненнән алып бүгенге көнгә кадәр Кызыл Армия, Ленин һәм Сталин җитәкчелегендә, гаять данлыклы юл үтте. Гражданнар сугышы елларында, чиктән тыш авыр шартларда илебезгә басып кергән барлык интервентларны тар-мар итте ул, һәм бай сугышчан тәҗрибә алды. Тыныч елларда безнең Кызыл Армиябез һаман чыныга, үсә барды, хәзерге заманның катлаулы сугыш сәнгатен тырышып үзләштерде, яңа кадрлар тәрбияләде, бай хәрби техника белән сугарылды, совет дәүләтенең куәтле кораллы көче булып үсеп җитте.

Бөек Ватан сугышының 20 ае — Кызыл Армия өчен авыр һәм җитди сыналу чоры булды. Авыр чигенү вакытларында да ул бирешмәде, актив оборона сугышлары алып барып, дошманның көчләрен хәлсезләндерде, әлсерәтте, аның техникасын һәм җанлы көчләрен кырды. Шуның белән бергә Верховный Баш Командующий иптәш Сталин җитәкчелегендә, хәлиткеч ударлар ясау өчен яңа, куәтле көч бертуктаусыз әзерләнде. Һәм бу көчнең хәрәкәткә китерелүен, аның нинди нәтиҗәләр бирүен хәзер дошман үз җилкәсендә татый, бөтен дөньядагы безнең барлык дусларыбыз, безнең союзникларыбыз Кызыл Армиянең бу һөҗүм көченә карап тирән сокланалар.

Кызыл Армиянең героик һөҗүм операцияләре планын төзүче һәм бу һөҗүмгә җитәкчелек итүче бөек полководецыбыз иптәш Сталин 1942 нче елның 7 нче ноябре приказында «Кызыл Армиянең яңа ударлары көчен дошманның татыр көне ерак түгел. Безнең урамда да бәйрәм булыр!»—дип язган иде. Бу көн килеп җитте. Кызыл Армиянең дошманга ударлары көннән - көн көчәя бара. Героик Кызыл Армиябезнең 25 еллык бәйрәме — безнең урамда инде башланган гомуми бөек бәйрәм белән бергә туры килә!

Кызыл Армиянең куәте бүгенге кебек һичкайчан да шулай зур, бөек булганы юк иде. Һәм совет халкының үз армиясенә, аның батыр сугышчыларына, аның кыю, оста командирларына, аның Верховный Баш Командующие даһи Сталинга мәхәббәте бу көннәрдә чиксез зур югарылыкка күтәрелде. Хезмәт ияләре батыр Кызыл Армиябез өчен коралларны, сугыш припасларын, азыкны көннән-көн күбрәк җитештерәләр, сугыш машиналары — танклар, самолетлар, пушкалар төзү өчен үзләренең саклык акчаларын бирәләр, үз араларыннан яңадан-яңа резервлар әзерләп фронтка, Кызыл Армиягә ярдәмгә җибәрәләр.

Халык һәм армия, фронт һәм тыл бездә бер бөтен. Шушындый бердәм, куәтле көчкә ия булган ил һичбер вакытта да җиңелмәс! Бу көч, һичшиксез, кабахәт фашизмны илебез чикләреннән куып чыгарыр һәм тәмам тар-мар итәр!

Без үзебезнең җиңәчәгебезгә нык ышанабыз. Кызыл Армиянең хәзерге зур уңышлары безнең бу ышанычыбызны тагын да көчәйтәләр. Ләкин бу уңышлар безне һич тә тынычлануга алып бармаска тиеш. Бу турыда, безнең Верховный Баш Командующиебыз иптәш Сталин Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән кичә, 23 нче февральдә чыгарган приказында аеруча кисәтү ясап үтә. Фронтларда безнең гаять зур уңышларыбызны санап чыкканнан соң, иптәш Сталин шушы сүзләрне әйтә: «Немец фашистлары армиясе Кызыл Армиядән алынган ударлар нәтиҗәсендә кризис кичерә. Ләкин бу әле — ул яңадан айный алмас дигән сүз түгел. Немец басып алучыларга каршы көрәш әле бетмәгән,—ул әле җәелеп һәм кабынып кына бара. Немецлар безнең җиребезнең бер генә километрын булса да сугышмыйча ташлап китәрләр дип уйлау ахмаклык булыр иде... Дошман армияләренә куәтле ударлар ясалды, ләкин әле дошман җиңелмәгән. Немец басып алучылар ярсынып каршылык күрсәтәләр, контратакаларга күчәләр, оборона чикләрендә тотынып калырга маташалар һәм аларның яңа авантюраларга баруы мөмкин».

—Бер генә минутка да тынычланмаска, һич тә масаймаска! — иптәш Сталин бездән шуны таләп итә.

—Дошманга ударларны тагын да көчәйтергә! — иптәш Сталин бездән шуны таләп итә.

—Һәркайда һәм һәр урында дисциплинаны, тәртипне һәм оешканлыкны бертуктаусыз ныгытырга! — иптәш Сталин бездән шуны таләп итә.

—Һөҗүм итеп баручы Кызыл Армиягә барлык көч белән, барлык средстволар белән булышлык итәргә! — иптәш Сталин бездән шуны таләп итә.

Бу таләпләрне фронтта һәм тылда намус белән үтәү—дошманны изге совет җирләреннән куып чыгару һәм аны тәмам тар-мар итү эшен тәэмин итәчәк.

Немец оккупантларын тар-мар итү һәм аларны ватаныбыз чикләреннән куып чыгару өчен Ленин байрагы астында, Сталин җитәкчелегендә—алга!

„ЯҢА ТОРМЫШ“ КОЛХОЗЫНДА

Актаныш районының «Яңа тормыш» колхозы (председателе фронтовик иптәш Г. Галиев) членнары, барлык эшләрне дә фронттагыча җитез алып барулары нәтиҗәсендә, колхоз үткән елгы барлык авыл хуҗалыгы эшләрен һәм дәүләт алдындагы барлык йөкләмәләрне үз вакытында төгәл үтәде.

Хәзер биредә 1943 нче елда тагын да яхшырак эшләү өчен ныклы әзерлек бара. Колхоз язгы чәчүгә тулысынча әзер инде. Барлык авыл хуҗалыгы машиналарына һәм язгы чәчү вакытында кирәк булачак барлык инвентарьларга ремонт ясау тәгәлләнгән һәм бригадирлар тарафыннан актлар белән кабул ителгән. Алар яхшы урыннарда сакланалар.

Агротехника чараларыннан кар тоту, басуга тирес чыгару, көл җыйнау, чәчү орлыкларын эшкәртү эшләре тәмамланган. Колхозда 5 агротехника түгәрәге эшли. Түгәрәкләргә язгы кыр эшләрендә катнашучыларның барысы да йөриләр.

З. ЗАКИРОВА.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР СУМЫ, АХТЫРКА, ЛЕБЕДИН, МАЛОАРХАНГЕЛЬСК ШӘҺӘРЛӘРЕН АЛДЫЛАР

1) 23 нче февральдә Украинада безнең гаскәрләр, һөҗүмне дәвам иттереп, СУМЫ, АХТЫРКА, ЛЕБЕДИН шәһәрләрен алдылар.

2) Курск өлкәсендә безнең гаскәрләр каты сугыштан соң МАЛОАРХАНГЕЛЬСК шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

23 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

23 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак Н-че часть сугышчылары бик каты сугышта 150 немец автоматчигын кырдылар һәм дошманның 2 танкысын, бер самоход орудиесен, 20 автомашинасын юк иттеләр. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 18 пулемет, 100 дән артык автомат һәм күп сугыш припаслары бар.

* * *

Краматорскаядан төньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть сугышчылары бер эшчеләр поселогы районында дошманның бер батальон мотопехотасын тар-мар иттеләр һәм 8 танкысын сафтан чыгардылар. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр, кинәт һөҗүм ясап, халык яши торган бер зур пунктны алдылар. Немецларның каршылык күрсәткән гарнизоны бөтенләй юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Грайвороннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүм алып бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бу пунктларның берсе өчен булган сугышларда немецларның бер полкка якын пехотасы юк ителде. Сугыш припаслары складлары, әйбер һәм азык складлары кулга төшерелде.

* * *

Курскидан төньяктарак безнең частьлар халык яши торган һәм көчле итеп ныгытылган күп кенә пунктларны алдылар. 600 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Пленныйлар алынды. Икенче бер участокта совет подразделениеләре дошманның тылына барып чыктылар һәм, чолгап алу куркынычы тудырып, немецларны чигенергә мәҗбүр иттеләр. Гитлерчылар, материаль частьларын ташлап калдырып, ашыгыч рәвештә чигенделәр.

* * *

Кубаньда безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Н-че часть сугышчылары гына да 18 орудие һәм зур сугыш припаслары складын кулга төшерделәр.

* * *

Төньяк-көнбатыш фронтта безнең очучылар бер көн эчендә һава сугышларында дошманның 12 самолетын бәреп төшерделәр. Шуның өстенә зенит артиллериясе уты белән немецларның 3 самолеты юк ителде.

* * *

Калинин өлкәсе партизаннарының бер отряды сан ягыннан өстен булган дошманга каршы сугышта 200 гә якын немец-фашист оккупантларны юк иткән. Икенче бер отрядның партизаннары төнлә белән бер тимер юл разъездына кинәт һөҗүм ясаганнар. Барлык тимер юл корылмалары җимертелгән, ике күпер һәм берничә урында тимер юл шартлатылган.

* * *

Ворошиловград өлкәсе Белолуцк авылында кеше аңгаучы гитлерчылар дистәләрчә кешеләрне үтергәнче газаплаганнар. Фашист палачлар, врач Федосья Дубинскаяны, укытучы Мария Чернышеваны, колхозчы Иван Яровойны, аның хатынын, кызын, киленен, бу соңгысының ике кечкенә баласын һәм башка күп кешеләрне атканнар. Немецлар 120 дән артык колхозчы йортын яндырганнар, көтепханәне юк иткәннәр, больницаның барлык җиһазларын талап бетергәннәр. Авылдан чигенер алдыннан гитлерчы кабахәтләр картларны, хатын-кызларны һәм балаларны — барлыгы 90 лап кешене чиркәүгә кертеп бикләгәннәр. Чиркәүне шартлатыр өчен бандитлар бөтенесен әзерләп бетергән булганнар. Һәммә яктан да авылга бәреп кергән Кызыл Армия частьлары немец ерткычларының бу явыз ниятьләрен эшкә ашыруга комачауладылар.

23 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

23 нче февральдә **Украинада** безнең гаскәрләр, һөҗүмне дәвам иттереп **Сумы, Ахтырка, Лебедин** шәһәрләрен алдылар, шулай ук район үзәге һәм тимер юл станциясе **Краснопольены**, халык яши торган зур пунктлардан һәм тимер юл станцияләреннән **Нижняя Сыроватка" ны, Верхняя Сыроватканы** һәм **Боромляны** алдылар.

Курск өлкәсендә безнең гаскәрләр каты сугыштан соң **Малоархангельск** шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

* * *

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

Безнең кораблълэр Баренц диңгезендә дошманның 8.000 тонна авырлыктагы бер транспортын батырдылар.

* * *

22 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 9 артиллерия һәм 6 миномет батареясының утын бастырдылар, бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар, Н-че часть подразделениеләре, дошман урнашкан урынга бәреп кереп, штык сугышыннан соң халык яши торган, ныгытылган пунктны алдылар. Сугыш кырында дошманның 200 гә якын үле гәүдәләре калды. 4 орудие, 16 пулемет, 5 миномет һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер пунктны алган чакта 180 немец солдаты һәм офицеры юк ителде. 2 орудие, 3 транспортер, 11 пулемет, бер корал складын һәм бер сугыш припаслары складын кулга төшерелде.

* * *

Красноармейское районында безнең гаскәрләр дошманның бик каты контратакаларын кире кайтардылар. Бу районга немецлар бик күп танклар һәм мотопехота туплап, әһәмиятле коммуникацияләрне кире кайтару өчен бөтен көчләре белән тырышалар. Безнең частьлар гитлерчыларның басымын тоткарлыйлар һәм аларны зур югалтуларга дучар итәләр. Бер көн эчендә генә дә дошманның 30 танкысы зарарланды һәм яндырылды, гаскәрләр төялгән 100 гә якын автомашинасы юк ителде.

(Ахыры 4 нче биттә).

ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

ХӘРБИ КОМИССАРИАТЛАРНЫҢ ҺӘМ БАШКА ОЕШМАЛАРНЫҢ РАБОТНИКЛАРЫН ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНЫҢ ПОЧЕТ ГРАМОТАСЫ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮ ТУРЫНДА

Ватан сугышы чорында Кызыл Армия өчен кеше һәм материаль ресурслар әзерләү һәм мобилизацияләү буенча партиянең һәм хөкүмәтнең заданиеләрен уңышлы үтәгән өчен Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең егерме биш еллыгын истә калдыру өчен түбәндәгеләрне Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет Грамотасы белән бүләкләргә:

1. Нина Ивановна **Абгарова** — хирург-врач, Бауман райвоенкоматы медкомиссиясе члены.

2. Фәүзия **Әхсәнова** — Яңа Писмән районы, Зай-Каратай авыл советы башкарма комитеты секретаре.

3. Иосиф Семенович **Алмаев**—ТАССР НКВД бүлеге начальнигы.

4. Даниил Семенович **Анно** — политрук, Столбище районы военкомы.

5. Иван Осипович **Антропов** — всевобуч взводы командиры, Шөгер районы райлесхозының хуҗалык бүлеге мөдире.

6. Шәриф Әсгадулла улы **Әсгадуллин**—всевобуч командиры, Арча районының Күпербаш тулы булмаган урта мәктәбенең военругы.

7. Алтынбек **Әхметов** — Калинин районы, Ворошилов исемендәге колхоз председателе.

8. Владимир Александрович **Баталин** — всевобуч батальоны командиры, НКПП ның макарон фабрикасы баш инженеры.

9. Әнвәр Исхак улы **Батыршин**—ВКП(б) ның Октябрь райкомы хәрби бүлеге мөдире.

10. Ксения Ивановна **Березина** — Октябрь районы, Чулпан больницасы врачы, райвоенкомат медкомиссиясе члены.

11. Виктор Васильевич **Бесходрный** — өлкән лейтенант, Татарстан АССР военкоматының укучыларны хәрби яктан әзерләү инспекциясе начальнигы.

12. Михаил Абрамович **Блюминцев** — ВКП(б) Өлкә Комитетының хәрби бүлеге мөдире.

13. Иван Макарович **Борзин** — всевобуч ротасы командиры, Казан энергокомбинатның ВОХ отряды командиры.

14. Николай Иванович **Буртовой** — политрук, Тәтеш районы военкомы.

15. Мазимә Зәйни кызы **Вафина** — Кайбыч районы, Чирмешән авыл советы башкарма комитеты секретаре.

16. Нәкыйп Вафа улы **Вафин** — Балтач районы, Алан авыл советы башкарма комитеты председателе.

17. Михаил Степанович **Власов** — всевобуч взводы командиры, шорный фабриканың ОТК начальнигы.

18. Павел Егорович **Воронцов**—Октябрь районы, Имоткин авыл советы башкарма комитеты председателе.

19. Гани Габдрахман улы **Габдрахманов**—Балтач районы, «Кызыл Тау» колхозы председателе.

20. Заһира Гайнан кызы **Гайнанова** — Балтач районы, Килеев авыл советы башкарма комитеты председателе.

21. Салих Гали улы **Галиев** — всевобуч пункты начальнигы, Арча районы, «Кызыл Масра» артеле мастеры.

22. Мәйсәрә Зариф кызы **Галимова** — Балтач райвоенкоматы медкомиссиясе члены. Балтач больницасы врачы.

23. Яков Михайлович **Галкин** — Питрәч районы, эшче - крестьян милициясе начальнигы.

24. Иван Васильевич **Греков** — батальонный комиссар, эвакогоспиталь начальнигы ярдәмчесе.

25. Александр Иванович **Гриньков** — ВКП(б) ның Ленин райкомы секретаре.

26. Гавриил Никанорович **Гришин** — III нче ранг интендант, Татарстан АССР военкоматының III нче бүлеге начальнигы ярдәмчесе.

27. Иван Иванович **Грищенко** — II нче ранг техник-интендант, Октябрь райвоенкоматының I нче бүлеге начальнигы.

28. Андрей Николаевич **Гусев** — АБТ мастерскойларының электрҗиһазлар буенча бригадиры.

29 Кирилл Григорьевич **Гуськов**—Арча районы, Платов авыл советы башкарма комитеты председателе.

30. Александра Григорьевна **Дегтярова**—Ленин райвоенкоматы медкомиссиясе врачы, 5 нче номерлы поликлиниканың хирург врачы.

31. Григорий Петрович **Долганов** — III нче ранг интендант, Татарстан АССР военкоматының финанс бүлеге начальнигы.

32. Дмитрий Тимофеевич **Дубровин** — политрук, Буа районы военкомы.

33. Александр Николаевич **Евдокимов**—I нче ранг интендант, Татарстан АССР ның хәрби комиссары.

34. Николай Алексеевич **Епанешников**—АБТ мастерскойларының машиналар җыю буенча бригадир-слесаре.

35. Нәҗип Кашшаф улы **Җаббаров**—кече лейтенант, Кызыл юл райвоенкоматының өлкән инструкторы.

36. Анастасия Михайловна **Зайцева** — Кызыл юл райвоенкоматының хатын-кызлар советы председателе.

37. Израиль Вульфович **Зак** — III ранг интендант, Чистай шәһәре военкоматының I нче бүлеге начальнигы.

38. Петр Иванович **Захаров**—ВКП(б) ның Юдино райкомы секретаре.

39. Николай Михайлович **Земляницын**—Бөгелмә больницасының өлкән врачы, райвоенкоматның врачлар комиссиясе председателе.

40. Галиәхмәт Зыятдин улы **Зыятдинов**—АБТ мастерскойларының 1 нче номерлы цех бригадиры.

41. Анна Назаровна **Золотарева** — Кызыл Армия начсоставы хатыннарының Киров райвоенкоматы янындагы советы председателе.

42. Василий Александрович **Зубарев**—всевобуч полкы командиры, Н-че заводның ОТК начальнигы.

43. Василий Михайлович **Зубов**—ВКП(б) ның Бөгелмә райкомы хәрби бүлеге мөдире.

44. Хафиза Мәхмүт кызы **Измайлова**—Столбище больницасы врачы, райвоенкомат медкомиссиясе члены.

45. Михаил Антонович **Калиновский**—АБТ мастерскойларының 4 нче номерлы монтаж цехы начальнигы.

46. Николай Андреевич **Калмыков**—Киров районының всевобуч ротасы командиры, Н-че заводның электро-механигы.

47. Андрей Николаевич **Калугин**—II нче ранг техник-интендат, Казан шәһәре Сталин райвоенкоматының I нче бүлеге начальнигы.

48. Татьяна Николаевна **Карамова**—Алабуга районы, Морты авыл урта мәктәбе директоры.

49. Хафиз Касим улы **Касимов**—всевобуч ратосы командиры, Кызыл юл районы, Татчишмә сельпосы председателе.

50. Василий Захарович **Квашнин**—Октябрь районы, «Красная Эра» колхозы председателе.

51. Афанасий Семенович **Клесев** — ВКП(б) ның Дзержинский райкомы хәрби бүлеге мөдире.

52. Алексей Васильевич **Козлов**—ВКП(б) ның Чистай шәһәр комитеты хәрби бүлеге мөдире.

53. Михаил Федорович **Кюмков**—всевобуч полкы командиры, Н-че заводның директорының охрана буенча ярдәмчесе.

54. Яков Георгиевич **Корнилов** — Кайбыч районы, Надежда авыл советы башкарма комитеты председателе.

55. Николай Яковлевич **Краснов**—Октябрь районы, «Ерепкино» колхозы председателе.

56. Аркадий Иванович **Кудрявцев**—I нче ранг техник интендант, Свердлов райвоенкоматының I бүлеге начальнигы.

57. Степан Дмитриевич **Кузнецов**—всевобуч командирының политик эшләр буенча урынбасары, ВКП(б) ның Бауман райкомы оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире.

58. Лидия Александровна **Лихачева**—Алабуга больницасының операция буенча өлкән сестрасы.

59. Михаил Александрович **Логинов**—Өлкән политрук, Казан шәһәренең Сталин районы военкомы.

60. Анастасия Семеновна **Лютова** — ВКП(б) ның Ленин райкомы хәрби бүлеге мөдире.

61. Иван Алексеевич **Максимичев**—всевобуч ротасы командиры, «Волга танкер» пароходчылыгының ВОХР начальнигы.

62. Елизавета Борисовна **Малкиель**—ВКП(б) ның Бауман райкомы секретаре.

63. Ираида Иосифовна **Мальцева**—Бөгелмә районы, Сокольский авыл советы башкарма комитеты председателе.

64. Екатерина Григорьевна **Матвеева**—Сталин районы поликлиникасының терапевт врачы, райвоенкомат медкомиссиясе члены.

65. Елена Ивановна **Матвеева**—райвоенкомат медкомиссиясе члены, Алабуга больницасының хирургия бүлеге мөдире.

66. Григорий Дмитриевич **Меданов** — Эшче-Крестьян милициясенең Казан шәһәрендәге 6 нчы бүлеге начальнигы.

67. Бранислава Марковна **Мексина**—ВКП(б) ның Молотов райкомы секретаре.

68. Зиннур Газиз улы **Миңлегалиев**—ВКП(б) Өлкә Комитетының хәрби бүлеге мөдире урынбасары.

69. Максим Никитич **Мишнев**—подполковник, Татарстан АССР военкоматының политбүлек начальнигы.

70. Вера Ивановна **Набуйщикова** —Молотов райвоенкоматының медкомиссиясе члены, II нче номерлы поликлиниканың тирапевт врачы.

71. Иван Никифорович **Никифоров**—Чүпрәле районы, Звездино авыл советы башкарма комитеты председателе.

72. Иван Яковлевич **Новиков**—всевобуч взводы командиры, автогараж җиһазлары заводының электромонтеры.

73. Тихон Андреевич **Осипов**—Октябрь районы, Октябрь МТС ының политбүлек начальнигы.

74. Ефим Осипович **Павлов**—I нче ранг техник интендант, Балык бистәсе районы военкомы.

75. Анатолий Яковлевич **Петрухин**—лейтенант, Питрәч районы военкомы.

76. Зинаида Акимовна **Прокофьева**—«Динамо» спорт җәмгыяте республика советының җаваплы секретаре.

77. Яков Павлович **Рохлин**—өлкән лейтенант, Минзәлә районы военкомы.

78. Абдрахман Сәйфетдин улы **Сәйфетдинов**—ВКП(б) ның Кызыл йолдыз райкомы хәрби бүлек мөдире.

79. Сәйфулла **Сәйфетдинов**—Саба районы, Шәкшә авыл советы башкарма комитеты председателе.

80. Михаил Михайлович **Сапугов**—НКРП ның Н-че заводы инженеры.

81. Сабирҗан Сафиулла улы **Сафиуллин**—Чүпрәле районы, «Йолдыз» колхозы председателе.

82. Шамиль Шакир улы **Седаев**—ВКП(б) ның Чистай шәһәр комитеты секретаре.

83. Алексей Григорьевич **Селехов**—I нче ранг техник интендант, Татарстан АССР военкоматының III нче бүлеге начальнигы ярдәмчесе.

84. Мария Николаевна **Семенова**—Татарстан республикасы военкоматының өлкән машинисткасы.

85. Владимир Михайлович **Сенько**—всевобуч взводы командиры, Зөядәге 9 нчы номерлы төрмә надзирателе.

86. Михаил Иванович **Сергеев**—Яңа Писмән райвоенкоматының всевобуч буенча өлкән инструкторы.

87. Наталия Ивановна **Соколова**—райвоенкомат медкомиссиясе члены, Тельман больницасы врачы.

88. Иван Степанович **Спирин**—Балык бистәсе райвоенкоматының II нче бүлек начальнигының ирекле рәвештә хезмәткә алу буенча ярдәмчесе.

89. Борис Федосеевич **Тарасов**—Татарстан АССР военкоматының I нче бүлеге начальнигы ярдәмчесе.

90. Алексей Порфирьевич **Тимесков**—II нче ранг техник-интендант, Казан шәһәренең Ленин райвоенкоматының I нче бүлеге начальнигы.

91. Иосиф Елисеевич **Ткачук**—I нче ранг техник-интендант, Юдино районы военкомы.

92. Ростислав Александрович **Ульяновский**—всевобуч командиры, Октябрь районы леспромхозының плановигы.

93. Александр Михайлович **Усанов**—райвоенкомат медкомиссиясе члены, Кайбыч больницасының хирург-врачы.

94. Василий Филиппович **Усенков**—өлкән лейтенант, Чүпрәле райвоенкоматының беренче бүлеге начальнигы.

95. Самат **Фарушкин**—АБТ мастерскойларының җыю һәм ремонт буенча бригадиры.

96. Хәмит Фагих улы **Фатихов**—НКВД ның Кызыл йолдыз район бүлеге начальнигы.

97. Зәйнәп Разетдин кызы **Фәхретдинова**—Свердловск райвоенкоматының медкомиссия члены, II нче номерлы поликлиниканың тирапевт врачы.

98. Василий Степанович **Федоров**—Осоавиахимның Бөгелмә районындагы укчылар клубы начальнигы.

99. Николай Дмитриевич **Федотов**—Казан шәһәре, хезмәт ияләре депутатларының Свердловск район советы башкарма комитеты председателе.

100. Петр Яковлевич **Фролов**—политрук, Чистай шәһәре военкомы.

101. Вәгыйз Хафиз улы **Хафизов**—Яңа Писмән районы, Зәй Каратай авыл советына караган «Уңыш» колхозы председателе.

102. Константин Кириллович **Хованов**—всевобуч батальоны командиры ярдәмчесе, төзү трестының тәэминат конторасының оператив бүлеге начальнигы.

103. Яков Максимович **Хурнов**—АБТ мастерскойларының 4 нче номерлы цех бригадиры.

104. Ефим Николаевич **Чаловский**—Бондюг райвоенкоматы медкомиссиясе члены, Бондюг больницасының баш врачы.

105. Евгения Викторовна **Черновская**—Кызыл Армиянең начальниклар составы хатыннарының Ленин райвоенкоматы янындагы советы председателе.

106. Михаил Семенович **Чумаков**—Тельман районы, Кече Сөнчәләй авыл советы башкарма комитеты председателе.

107. Хәсән Шәйдулла улы **Шәйдуллин**—Бөгелмә районының Исаково авыл советына караган «Тигез басу» колхозы председателе.

108. Шәриф **Шәймиев**—Калинин районы, Пучы авыл советына караган «Беренче Май» колхозы председателе.

109. Борис Шакир улы **Шакиров**—ВКП(б) ның Саба райкомы секретаре.

110. Алексей Константинович **Шаповал**—Казан шәһәренең Бауман районы военкомы.

111. Зыятдин Шәрәфетдин улы **Шәрәфетдинов**—Арча районы, Урта Пшалым авыл советына караган «Көлтәс» колхозы председателе.

112. Александра Ивановна **Шепкова**—Кайбыч районы, Ульяновский урта мәктәбе директоры.

113. Антонина Дмитриевна **Шестакова**—начальниклар составы хатыннарының Молотов райвоенкоматы янындагы советы председателе.

114. Серафима Валентиновна **Шумилова**—Киров райвоенкоматының медкомиссиясе члены, шәһәрнең икенче больницасы хирург-врачы.

115. Василий Тимофеевич **Юдин**—политрук, Куйбышев районы военкомы.

116. Иван Федорович **Ядунин**—НКВД ның Октябрь район бүлеге начальнигы.

117. Прокопий Сергеевич **Ямков**—ВКП(б) ның Октябрь райкомы секретаре.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе
Г. ДИНМӨХӘМЕТОВ.

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Секретаре
С. СӘЕТГӘРӘЕВ.

Казань, Кремль, 22 февраль, 1943 ел.

Рәсемдә: сулда—азат ителгән пунктның халыклары Кызыл Армия частьларын каршы алып озата баралар. Уңда—немец оккупантлар авылдан сөрелгәч колхозчылар үз йортларына кайталар.

ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТЛАР СОЮЗЫНДАГЫ БАРЛЫК ХАЛЫКЛАРНЫҢ УЛЛАРЫ СОВЕТЛАР ВАТАНЫ ӨЧЕН СУГЫШКА БАРАЛАР. ЯШӘСЕН КЫЗЫЛ АРМИЯ — СССР ХАЛЫКЛАРЫНЫҢ ТУГАНЛЫГЫ ҺӘМ ДУСЛЫГЫ АРМИЯСЕ!

(ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ЛОЗУНГЛАРЫННАН)

БЕЗНЕҢ ЯКТАШЛАР—ГЕРОЙЛАР

Орденлы батыр

Шакирга бурыч кискен куелган: дошман резервлары кайдалыгын һәм каян килүен белергә. Һавада дошман зениткалары эш итеп ут җәтмәсе үрәләр. Шакир, кызыл-кызыл булып шартлаган снарядлар арасыннан маневр ясап, дошман тылына ыргылып чыга, һәм аның алдында, үрмәкүч пәрәвезедәй, юллар ачылып китәләр; юлларда дошман автомашиналары, гаскәрләр, якын урманда миномет, артиллерия нокталары... Укчы-бомбардир боларның һәммәсен дә картага төшерә бара.

Шакир разведка мәгълүматларын генералга китерде. Алар зуручa кыйммәтлеләр иде...

Бер шулай ул, чалт аяз көндә һавага күтәрелеп, дошман ягына разведкага китте. Ул дошманны югарыда күзәп озак йөрде. Аның картасында бер-бер артлы билгеләр арта барды. Разведка уңышлы иде. Ул кайтыр юлга борылды. Көтмәгәндә каршысына кинәт «Хеншел—126» килеп чыкты, Шакирны атакалады. Шакирның самолеты коралланмаган. Шакир хәйләгә тотынды. Ул самолеты белән «Хеншел» нең канат астына чумды. Мондый хәлдә «Хеншел» чарасыз калды.

«Хеншел», түгәрәк ясап әйләнеп килде дә тагын атакалый башлады. Бу юлы Шакир түбәнгә таба атылып төште һәм дошман ударыннан ычкынды.

«Хеншел» аны шулай биш тапкыр атакалады. Җиргә җитәргә инде ике йөз метр гына калган иде. Шул вакыт каяндыр безнең истребитель килеп чыкты һәм «Хеншел» нең үзен атакага алды, аны куып китте.

Разведкада бай материаллар туплаган Шакир үз аэродромына килеп утырды.

Икенче вакыт, аңар дошманның хәрби объектларын яндыру бурычы куелды. Шакир, немецларның көчле зенит уты аркылы үтеп, дошман өстенә ут илтеп ташлады. Түбәндә янгын котырынып дөрләргә тотынды. Дошман арасында дәһшәт купты. Ләкин Шакирның үз самолетына да ут кабынды. Ул ут белән озак көрәште, ахырында аны сүндерде һәм кайтыр юлга чыкты. Аңар һавада иптәшләре каршы очрадылар—алар, дөрләгән утка карап, бомбалар алып баралар иде.

Дошманны кыруда батырлыгы һәм осталыгы өчен, кече лейтенант Шакир Фәхретдинов Ленин ордены белән бүләкләнде.

Кече лейтенант **П. ГОРШКОВ.**
ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ.



ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. Каты сугыш вакытында танк ротасының командиры һәлак булгач, лейтенант А. И. Матренин рота белән командалык итүне үз өстенә алды һәм сугыш заданиесен үтәде. Инициативалылыгы һәм батырлыгы өчен ул Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде. Сугышка кадәр иптәш А. И. Матренин Татарстан АССР Наркомземында чертежник булып эшләгән иде.

ТАСС фотохроникасы.

Гвардеецлар

Икенче укчы взводның бер семьядай яшәүче сугышчылары арасында гвардеецлардан Габдулла Хисмәтуллин һәм Сөләйман Гыйниятуллин иптәшләр мактаулы урын тоталар. Аларның батырлыклары турында сугышчылар бәетләр чыгаралар. Аларның кыюлыклары турында башка частьларда да беләләр.

Алар дошманга каршы каты бәрелешләрдә һәрвакыт җиңеп чыктылар. Күптән түгел Сөләйман сугышчан сакчылыкта тора иде. Окоп алдында кар белән капланган тигез кыр сузылып ята. Сөләйман шул чакта бер кечкенә агач янында кинәт кардан ясалган шарны күрә. Сөләйман: «Бу нинди гаҗәп нәрсә? Карны тәгәрәтеп кеше сурәте ясарга уйладылармикәнни?» дип уйлый. Берничә минуттан соң кар шары озынчарак булып әверелә. Сөләйман җиргә ятә һәм кар шарына винтовкасын төзи һәм атып җибәрә. Шул секундта ук кар шары урманга тәгәрәп китә. Аның артында карда кан эзе кала. Немецларның разведчигы шул рәвештә безнең алгы позицияләребез янына килергә уйлаган була. Сөләйман «Качып котыла алмассың, кабахәт җылан!» дип кычкыра да, яңадан атып җибәрә. Немец кар шары эченнән сикереп чыга, ләкин шул вакытта ук йөз түбән егыла. Шулай итеп немецлар разведчигының хәйләсе барып чыкмый.

Икенче взводның батыр сугышчылары дошманны һәрвакыт шулай кыйныйлар. Бер вакыт дошманның минасы төшеп урмандагы телефон чыбыгы өзелә. Взвод командиры сугышчылардан Габдулла Хисмәтуллинга телефон линиясен төзәтергә куша. Хисмәтуллин бик тиз арада карлы кырдан йөгереп урманга кереп китә һәм телефонның бозылган урынын таба. Телефон чыбыгы берничә җирдән өзелгән була. Ул җиргә иелә дә чыбыкларны ялгарга керешә. Кинәт аның баш өстеннән пуляләр сызгырып үтә башлый. Хисмәтуллин башын бераз күтәреп карагач, әрәмәлек артына яшеренгән өч немецны күрә. Баштарак ул каушабрак калса да, соңыннан өч немецка каршы бер үзе сугышырга карар бирә. Һәм винтовкасын алып бер-бер артлы немецларның өчесен дә үтерә. Хисмәтуллин телефон линиясен бик тиз төзәтеп, үзенең дуслары янына исән-сау кайта.

Безнең якташларыбыз менә шулай сугышалар. Алар дошманны ярсулы рәхимсезлек белән кыйныйлар.

Майор **ДМИТРИЙ ТАТЬЯНИН.**

Броняны җиңгән осталык

Урман аланына биш немец танкы килеп чыкты. Шул вакыт, урман авызына бик яхшы итеп яшеренгән танкка каршы ата торган безнең бер орудие телгә килде.

Дошман танклары һаман һөҗүм итә бирделәр. Алар Нуруллин орудиесе торган җиргә якын ук килеп җиттеләр. Нуруллин кулын болгады һәм команда бирде:

— Туры төзәп, ут ач!

— Була, туры төзәп—ут!—һәм дошман танклары өстенә бер-бер артлы снарядлар очып китте. Бер снаряд алгы танкның ягулык тутырган багы турысына барып төште. Танк җиңелчә генә чайкалып китте һәм гөлт итеп яна башлады.

Менә, бер танк кызу гына барган җирдән кинәт сөрлегеп китте. Ул, берничә талпынып куйды да, шып туктады. Аның чылбыры өзелде. Туры төзәп атуның дәһшәтен бик яхшы белеп һәм тиз арада ике танкларының сафтан чыгуын, үзләренә дә шундый язмыш җитүен күргәч, калган өч танк өчесе өч якка качтылар да, кире урман эченә кереп киттеләр.

Безнең укчылар шуны гына көтеп торалар иде дә, укчылар өчен юл ачылды. Алар, алан аша чыгып, дошман өстенә кыю рәвештә бардылар һәм, немецлар оборонасын кисеп, аларның ДЗОТ ларына бәреп керделәр.

Шундый уңышлы эшләре өчен, орудие командиры коммунист өлкән сержант иптәш Гыйнадулла Нуруллин берничә тапкыр рәхмәт алды һәм ул «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнде.

Г. ГЫЙЛЬМАНОВ.
ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ.

☆

КӨНБАТЫШКА, БАТЫР СУГЫШЧЫ!

Әй, ышанычы халыкның,
Әй, Совет иле нуры, —
Ыргыл, баһидар сугышчы,
Көнбатышка туп-туры!

Өнендә дә, төшендә дә
Уйла көнбатыш ягын;
Безнең бурыч юк итүд:
Палачларын дөньяның!

Анда ачлык-ялангачлык
Һәм палач котырып яши,
Анда безнең туганнарның
Җаннарын үлем ашый.

Көнбатышта газаплана,
Сыкрый безнең аналар,
Сине сагынып җылый-җылый
Көтә газиз балалар!

Анда үзәге өзелә
Гүзәл кызларыбызның.
Палачлар ашый икмәген
Изге кырларыбызның.

Көнбатышта, әй сугышчы,
Көтә сине халыклар,
Син азат ит халыкларны
Анда шатлык алып бар!
Анда юк зур якты кояш,
Анда ямьсез төн генә.
Син коткармасаң аларны
Коткарыр соң кем генә?!
Әй, ышанычы халыкның,
Әй, мәңге сүнмәс нуры,—
Ыргыл, баһидир сугышчы,
Көнбатышка туп-туры!
Ыргыл, баһидир сугышчы,
Кичеп ут диңгезләрен,
Көл итеп сугыш утында
Фашистларның үзләрен!
Коткарыйк, тизрәк сугышчы
Туганнарны коткарыйк,
Көнбатышка мәңге сүнмәс
Зур кояш булып барыйк!

Техник-лейтенант М. САДРИ.

ДАНЛЫКЛЫ ЯКТАШ

Аның күкрәгендә ике орден балкый. Берсе—«Кызыл Йолдыз» ордены, икенчесе—«Кызыл Байрак» ордены. Данлыклы якташ Михаил Прокофьевич Лукоянов куркуны белми, үзенең тормышын кызганмый торган чын патриот.

Лукоянов Түбән Ослан авылыннан (Югары Ослан районы) 1941 нче елның сентябрендә үк китә һәм шул көннән бирле өзлексез сугыш кырында йөри, иң куркыныч авыр шартлар эчендә сугышчыларга беренче ярдәмне күрсәтә һәм аларны исән-сау ут эченнән алып чыга. Үз эшенең мастеры булган Лукоянов зур саклык белән эшли. Куркусызлык белән саклык бу данлыклы якташта икесе дә бар. Шуңа күрә дә, ул бер генә минутка да сафтан чыкмый, яраланмый, үзенең мактаулы эшен дәвам иттерә.

Йөзгә якын командир һәм кызылармеецларга ут эчендә беренче ярдәмне күрсәтеп алып чыгуы һәм үлемнән алып калуы өчен ул Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

Безнең якташ санинспекторлык эшенең мастеры гына да түгел, ул оста оештыручы да. Бу осталыкны ул Смоленск өлкәсендә булган бәрелештә күрсәтә. Авылга немец бандитлары һөҗүм итәләр һәм үзләренең сан ягыннан өстенлекләреннән файдаланып, безнең частьны кысрыклыйлар һәм авылга керә башлыйлар. Безнең якташ Лукоянов тиз генә повар разведчик, связист кебек 10 лап сугышчыны оештыра. Бер пулемет алалар һәм дошманга каршы ут ачып каршы торалар. Көтелмәгәндә генә булган бу каршылык дошманны туктата, ун батыр үзләреннән күп тапкырлар өстен булган дошманны каушауга төшерәләр. Бу моменттан файдаланып, безнең часть контратакага күчә һәм фашистлар куыла, туздырыла, стратегик әһәмиятле авылга дошман кертелми.

Икенче орден — Кызыл Йолдыз ордены Михаил Прокофьевич Лукояновка әнә шул героик эше өчен бирелә.

Түбән Ослан колхозчылары, шулай ук Татарстанның барлык хезмәт ияләре үзләренең куркусыз батыр уллары Лукоянов белән горурланырга хаклылар.

Атаклы санинструкторга дан!

А. ӘХМӘТ.
ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ.

Кыюлык сугышчыны саклый

Миңа һәм минем иптәшләремә минем автоматым нык ярдәм итте. Вакыйга болай булды. Без, сигез разведчик, һөҗүм алдыннан дүрт артиллерия командирын дошман тылына озата идек. Разведкага таулык, куаклыклар арасыннан бара идек. Мин алда бара идем. Вакыт-вакыт туктыйм да тыңлыйм. Якка карaнам. Менә, бер вакыт, кар шытырдап, агач ботаклары селкенеп китте. Миннән 10—15 метр җирдә, куаклыктан немец чыгып килә.

Карасам, куаклыкта егермеләп немец солдаты. Мин бер якка, куаклык куерак урынга тайпылдым һәм нарат артына яттым. Бу вакытта кем алдан ут ачса, шул җиңә иде. Мин башлап очередь бирергә өлгердем, якындагы немецлар егылдылар. Калганнары кире әйләнеп кача башладылар. Алар, еланнар, дискта 71 патрон барлыгын, аның барысына да җитәчәген беләләр. Туктап аталар да, тагын йөгерәләр. Урманда, ату тавышлары гына ишетелеп тора.

«Эш тиз эшләнми, әкият кенә тиз сөйләнә»,—дигән халык мәкале бар. Ә биредә, киресенчә, сөйләп торуы озаграк, бәрелеш кыска. Тизлек һәм кыюлык бөтенесен хәл итә. Мин егермегә якын немецны күрдем, сугышка керештем. Шуны әйтергә кирәк, һәркем исенә төшерсен: кыюлык сугышчыны саклый. Әгәр дә мин куркып качкан булсам, немец пулясыннан үлгән булыр идем. Ә биредә немецлар качтылар. Мин, торып селкендем дә, үзебезнең төркемгә килеп кушылдым, күрсәткән кыюлык өчен, мин Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләндем.

Старшина **С. СМИРНОВ.**
ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ.

Совет Информбюросыннан

23 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

Лебедин шәһәренә керү юлларында Н-че часть сугышчылары дошманның көчле итеп ныгытылган бер терәк пунктын чолгап алдылар. Бирелүдән баш тарткан немецлар гарнизоны юк ителде. Бик каты сугыштан соң безнең гаскәрләр Лебедин шәһәрен алдылар. Икенче бер участокта безнең хәрәкәттәге отрядларыбыз 400 гә якын гитлерчыны юк иттеләр. Сугыш припаслары һәм төрле йөкләр төялгән 68 автомашина һәм күп повозкалар кулга төшерелде. Н-че часть сугышчылары, халык яши торган бер пунктны алган чакта, немецларның 3 танкысын, 5 орудиесен, 35 автомашинасын 70.000 авиабомбасын, 6.000 снарядын һәм 50.000 патронын кулга төшерделәр.

Курскидан төньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Немецлар Малоархангельск районына бик күп көчләр китерделәр һәм бу әһәмиятле пунктны ничек кенә итеп булса да үз кулларында тотып калырга маташтылар. Совет частьлары, гитлерчыларның каршылык күрсәтүен бастырып, 23 нче февральдә иртә белән шәһәрне һәм Малоархангельск тимер юл станциясен алдылар. Дошман гаять күп җанлы көчләрен һәм техникасын югалтты.

Украинаның бер районында хәрәкәт итүче отрядның партизаннары немецларның бер эшелонына каршы ут ачканнар һәм паровоз бригадасын юк иткәннәр. Йөртүчесез калган поезд станцияне үтеп китеп, бик зур тизлек белән барып, каршыга килә торган эшелонга бәрелгән. Һәлакәт нәтиҗәсендә составлар икесе дә җимерелгәннәр. Украинаның икенче бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды немецларның бер концентрация лагерена кинәт һөҗүм ясаганнар. Бу лагерьда совет гражданнары ябылган булган. Партизаннар лагерь сакчыларын үтергәннәр һәм барлык тоткыннарны азат иткәннәр.

* * *

Кызыл Армиянең 25 еллыгы турында Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказын Советлар Союзының хезмәт ияләре гаять зур күтәренкелек белән каршы алдылар. Массовый митингларда һәм җыелышларда эшчеләр, колхозчылар, совет интеллигенциясе—бөтен совет халкы, Кызыл Армиянең бөек полководецың—иптәш Сталинны чын күңелдән котлыйлар. Хезмәт ияләре Кызыл Армиянең сугышчан байракларны дан белән бизәгән һәм немец-фашист басып алучыларны җиңү өчен ныклы нигез салган сугышчыларга, командирларга һәм политработникларга мәхәббәт һәм сәлам сүзләре җибәрәләр.

Москва инструмент заводының иптәш Белянский җитәкчелегендәге цехларда эшчеләр приказны коллектив булып укыдылар Иптәш Сталинның «Дошманны Советлар иленнән массовый төстә куу башланды» дигән сүзләре аеруча шатлык белән каршы алынды. Күптән түгел Хезмәт Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән слесарь Суворов болай диде: «Безнең илебезнең хезмәт ияләре батыр Кызыл Армиябез өчен армый-талмый дәһшәтле корал эшләп чыгаралар. Иптәш Сталин безнең предприятиеләребезнең эшенә югары бәя бирде. Киләчәктә дә күп тапкырлар арттырылган энергия белән эшләрбез. Гитлер яуларын тәмам тар-мар итүне тизләтү өчен бөтенесен эшләрбез».

Подольск предприятиеләре эшчеләре, иптәш Сталинның приказы белән танышканнан соң, болай диделәр: «Кызыл Армиянең җиңүләре безне ватаныбыз хакына хезмәт батырлыкларына рухландыра. Немец басып алучыларга каршы көрәшнең әле тәмам булмаганлыгы, аның әле җәелеп һәм кабынып кына баруы турында иптәш Сталинның сүзләре безне, Кызыл Армиягә танкларны, самолетларны, коралларны һәм сугыш припасларын күбрәк бирү өчен, тагын да яхшырак эшләргә бурычлы итәләр».

Иваново шәһәрендә, директоры иптәш Лебедев булган заводның цехларында, күп кеше катнашкан митинглар булды. Бу завод январь аенда ВЦСПС ның һәм Җиңел Промышленность Халык Комиссариатының күчмә Кызыл Байрагын алган иде, ә февраль аенда айлык планын 109,8 процент итеп үтәде. Митингта катнашкан эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар фронтка ярдәмне тагын да көчәйтәчәкләренә ант иттеләр.

Англиядә Кызыл Армиянең 25 еллыгын бәйрәм итү

ЛОНДОН, 21 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, бүген Лондондагы иң зур бинада—Альберт Холлда Кызыл Армиянең 25 еллыгын бәйрәм итү булган. Бәйрәмдә Англия хөкүмәте членнары, союздаш илләр хөкүмәтләренең членнары, шулай ук дипломатия корпусы вәкилләре катнашкан. Англия армиясеннән вәкил булып күп кенә күренекле офицерлар, шул исәптән фельдмаршал лорд Горт килгән.

Чит ил эшләре министры Иден, тантаналы бәйрәмне ачып, залда булганнарга һәлак булган совет сугышчыларын бер минутлык тынлык белән искә алырга тәкъдим иткән.

Аннан соң сәхнәләштерелгән обзор башланган. Бу обзор Россиянең үзенең бөтен тарихы буена чит ил басып алучыларының һөҗүмнәрен ничек итеп кире кайтарганлыгын күрсәткән.

Бәйрәм тантанасында Англиянең чит ил эшләре министры Иден речь белән чыккан.

Җыелышта Совет илчесе иптәш Майский, шулай ук Лондондагы совет колониясе членнары катнашкан.

Рейтер агентлыгының хәбәр итүенчә, Кызыл Армиянең 25 еллыгы бүген Англиянең барлык зур шәһәрләрендә тантаналы төстә искә алынган. Шул уңай белән булган җыелышларда һәм митингларда Англиянең министрлары һәм башка җитәкче эшлеклеләре речьләр белән чыкканнар. Кардиффта баш министр урынбасары Эттли, Шеффилдта авиация промышленносте министры Стаффорд Криппс, Брайтонда эчке эшләр һәм эчке куркынычсызлык министры Моррисон, Нью-Кастелда хәрби производство министры Литтлтон, Манчестерда колонияләр министры Стэнли, Бристольда диңгез министры Александер, Бермингамда сәүдә министры Далкптон, Глазгода Ланкастер герцоглыгы канцлеры Дафт Купер речьләр сөйләгәннәр.

Лондонда һәм башка шәһәрләрдә булган тантаналарда сөйләнгән речьләрнең тулы эчтәлеге Рейтер агентлыгы тарафыннан өстәмә рәвештә тапшырылачак.

ИДЕННЫҢ ЧЫГЫШЫ

ЛОНДОН, 21 февраль. (ТАСС). Англиянең информация министрлыгының хәбәр итүенчә, чит ил эшләре министры Иден Лондонда Альберт Холлда Кызыл Армия көне уңае белән булган митингта речь белән чыккан. Иден болай дигән:

— Бу атнада безнең союзнигыбыз—СССР халкы—үзенең героик армиясе төзелүнең 25 еллыгын бәйрәм итә. Гали җәнап хөкүмәте миңа бу митингта речь сөйләргә, аның исеменнән һәм бөтен Англия халкы исеменнән Кызыл Армиянең батырлыгына тиешле бәяне бирергә тапшырды. Бу армиянең тревогалы күп айлар буена чигенүе вакытында безнең соклануыбыз һәм безнең мәхәббәтебез һәрвакыт һәм тулысынча шушы, нык каршылык күрсәтүче армиянең кешеләре ягында булды. Менә бүген инде алар үзләренең ныклы көрәшләренең җимешләрен күрәләр. Алар белән бергә без дә вакыйгаларның яңа борылышына һәм аларның өзлексез бара торган җиңүле һөҗүмнәренә шатланабыз. Сталинград өчен булган сугышта Кызыл Армия ясаган кебек шундый җимергеч ударны Германия армиясе үзенең озак ләвам иткән бөтен тарихы буена беркайчан да күргәне юк иде әле. Тагын да остарак булган җитәкчелек, тапын да остарак булган стратегия һәм тагын да остарак булган көрәш Гитлерга көчле удар ясады.

Безнең гомуми дошманыбызның мактанчык белдерүләрен без онытмадык, ә рус халкы беркайчан да онытмас. 1941 нче елның көзендә үк безне, совет армияләре җимерелде һәм юк ителде, дип ышандырырга маташканнар иде. Моннан 5 кенә ай элек әле Гитлер Германия халкына, минем гаскәрләрем Сталинградны алырлар, дип сүз биргән иде. Бүген исә Советлар Союзы армияләре Гитлерны Германия каршына үзенең чирек миллионнан артык иң яхшы гаскәрләренең һәлакәте өчен җаваплы кеше итеп китереп бастырдылар, чөнки Гитлерның уңышсыз җитәкчелеге нәтиҗәсендә аның армиясе совет сугышчыларының кискенлегенә һәм батырлыгына бәрелеп ватылды. Немецлар тарафыннан үткән елның бөтен җәе буена басып алынган бөтен территорияне генә түгел, бәлки яңа районнарны да Кызыл Армия 3 ай эчендә азат итте. Шуның өстенә Кызыл Армия Германия халкын немец гаскәрләренең җимерелүләре мөмкин икәнлеккә һәм тәртипсез рәвештә чигенергә мәҗбүр булуларына ышандырды. Без үзебезнең 8 нче армиябезнең дә моны Роммельга исбат иткәнлеге белән горурланабыз. Наполеон армиясе кебек, Гитлерның гаять зур армиясе рус патриотизмы белән, рус халкының иң авыр мохтаҗлыкларны да кичерә алуы белән, Россиянең киң мәйданы белән көч сынашып карарга маташуның үлем куркынычына бәйләнгәнлегенә ышанды.

Кызыл Армия көнендә без Кызыл Армиянең бөтен җитәкчелегенә, аның Сталин кул астындагы верховный командованиесенә — аның оста стратегиясе өчен, аның фронттагы генералларына — аларның бу стратегияне бик һәйбәт куллануы өчен, һәртөрле дәрәҗәдәге офицерларына — аларның гаскәрләргә батырларча һәм оста җитәкчелек итүләре өчен, аның унтер-офицерларына һәм солдатларына — аларның уңышсызлыкка очраганда какшамыйча нык торулары өчен һәм һөҗүмгә көчле омтылыш белән ташлануы өчен тиешле бәяне бирәбез. Без кызыл һава флоты сугышчыларына һәм коммуникацияләрдәге, тәэмин ителүдәге гаять зур кыенлыкларны җиңүдә булышлык итүчеләрнең барысына да тиешле бәяне бирәбез. Шул ук дәрәҗәдә без Советлар Союзы партизаннарының мәңге онытылмаслык батырлыкларына бәя бирәбез.

Миңа тагын бер мактауны өстәргә рөхсәт итегез. Буоын әчке характердагы мактау дип әйтергә мөмкин. Ул—Англиянең король һәм сәүдә флотлары кешеләренә — елның кайсы гына вакытында булса да, нинди генә һавада да төньяк юлының куркынычларын игътибарга алмыйча, безнең рус союзникларыбызга һәртөрле сугыш материаллары илтеп тапшырган кешеләргә без тиешле бәяне бирербез. Бу кешеләр Англия флотының иң батыр традицияләрен горурлык белән сакладылар.

Кызыл Армиянең үзенең ватанын уңышлы саклавында без агрессорга каршы берләшкән илнең тантанасын күрәбез. Дюнкеркта булган вакыйгалардан соң без, ялгыз булсак та, безнең беркайчан да бирелмәскә нык карар бирүебезгә каршы дошман һөҗүм башлаган көннәрдә үз атауларыбызда барлык англичаннарның йөрәкләрендә нинди рух булган булса, без совет халкының да шундый ук рух белән чолганып алынганлыгын күрәбез. Ләкин мин монда кисәтү ясарга тиешмен. Гитлерның хәрби җитәкчелеге җимерелгән урында хәзер Геббельсның бөтен хәйләсе эшкә кушылды.

Союзниклар арасында шикләнүләр тудыру өчен, дошманлык кабызу өчен һәртөрле маташулар булды һәм булачак. Бөтен иске-мыскылар яңадан өстерәп чыгарылды. Бу курчак театрында шактый зур урынны большевизм белән куркыту алып тора. Бәхеткә каршы безгә бу пычрак буяулар белән ясалган карачкыны тану кыен түгел. Бу — нацистлар режимының беренче көннәрендә килеп чыккан иске таныш. Аның эченнән инде күп кенә пычкы чүпләре коелган, ул инде Геббельсның хәйләләренә бик үк бирелми дә, ләкин һаман да әле бу карачкының хезмәтеннән файдаланалар.

Австрия басып алынган чакта, Чехословакияне кабып йоткан чакта, Польша куркыныч астында торган чакта Европаны куркыту өчен шуннан файдаландылар. Польшага мәңгелек дан булсын, — ул буйсынудан баш тартты.

Бу кызыл карачкы яңадан өстерәп чыгарылды һәм бу юлы инде аны икенче бер фигура белән бергә йөртәләр. Безгә Гитлерны Европа культурасын коткаручы дип санарга тәкъдим итәләр. Бу фигурага 1943 нче елны кайбер нәрсәләр җитеп бетми. Шулай ук оккупацияләнгән илләрдәге халыкка да бу маскарадны, битараф илләр кебек үк чынга алу кыен булыр.

Культураны коткаручы,—нинди көлке! Хәзерге кабахәт сугышның бердән-бер гаепләсе булган Гитлер 1940 нчы елны күп айлар буена һәм 1941 нче елның башында безне тезләндерә алмады. Без аның бөтен деньяда өстен булырга баруы юлында киртә булдык. Шуннан соң ул салкын кан белән, хәтта рәсми ультиматум бирми торып Советлар Союзына һөҗүм итте. Шуннан 2 елдан кимрәк вакыт элек ул аңа дуслык саклау турында аңа вәгъдә иткән иде. Ул шушы илгә һөҗүм итте. Үзенең палачлары белән бергәләп, бер нәрсәдә дә гаепләре булмаган йөз меңнәрчә чехларны, полякларны, грекларны, норвегиялеләрне, югославларны, голландиялеләрне, бельгиялеләрне, французларны, русларны кырган Гитлер, Варшаваны, Роттердамны, Белградны, Ковентрины, хисапсыз күп рус шәһәрләрен җимергән Гитлер, югары раса доктринасын игълан иткән, бөтен Европаны кол итәргә һәм немец әфәнде хакына ачлыктан үтерергә тиеш булган доктринаны игълан иткән Гитлер, хәтта үз илендә дә законнарны юк иткән Гитлер — менә шушы Гитлер культураны коткару ролен дәгъва итә. Бу кешенең культураны коткаруы өчен бары тик бер генә юл бар: ул Германиянең үз каршысына һәм бөтен деньяа каршысына үзе эшләгән явызлыкның коточкыч монументы булып, — шуның кебек икенче бер фигураның килеп чыгуына каршы вакытында чаралар күрергә кирәклеген кешелек деньясының һәрвакыт исенә төшереп тора торган монумент булып килеп бассын өчен аңа үзе тарафыннан төзелгән коточкыч нацистлар машинасын аны тәмам җимерелгәнчегә кадәр идарә итәргә мөмкинлек бирү.

Германия пропагандасының соңгы чорында тагын бер яңалык яңгырады: «Беразгына нык торыгыз һәм англо-сакслар һәм руслар бер-берләреннән аерылырлар».

Сез барыгыз да беләсез, бу өметләр инде җимерелделәр. Үткән елның май аенда без монда, Лондонда, союз турындагы Англия-Совет договорына кул куйдык. Без бу сугышта көчәр державаларын тәмам юк итү өчен бергәләшеп эшләргә сүз биреп кенә калмадык, бәлки тыныч вакытта безнең хезмәттәшлегебезгә нигез булачак тагын да киңрәк принциплар буенча килешүгә дә ирештек. Без сугыштан соңгы системаны төзү мәсьәләсендә килешүгә ирештек. Бу система Гитлерның «яңа тәртибе» гәүдәләндерә торган бөтен нәрсәләрне инкар итәчәк.

Гитлерның дошманнары чын мәгънәсе белән берләшкән милләтләр. Баш министр Сталинның 6 нчы ноябрь речендә Совет Социалистик республикалар Союзы исеменнән Гитлерга җавап бирелгән иде. Сталин әфәнде Англия, Советлар Союзы һәм Кушма Штатлары коалициясе турында сөйләде. Бу илләр, идеологияләре һәм структуралары төрлечә булуга да карамастан, гомуми дошманга — Гитлерга каршы көрәшәчәкләр.

Англия халкы бу программаны кабул итә. Без Сталин әфәнденең, Англия-Совет договоры безнең ике ил арасындагы мөнәсәбәтләрдә тарихи борылыш пунктын күрсәтә, дигән белдерүен кабул итәбез.

Хәзерге вакытта Англия һәм Америка гаскәрләре — Кызыл Армия белән коралдаш иптәшләре, авиация белән һәм хәрби флот белән берлектә, дошманны кире Европа континентына, без аны куып барачак урынга алып ташлау өчен Урта диңгез ярларында сугышалар. Союзникларның хәрби һава көчләре күчәр державалары гаскәрләрен тәэмин итүче заводларны һәм коммуникацияләрне торган саен көчлерәк җимерәләр.

Бүген без Кызыл Армияне, Александр Невский көннәрендә Тефтон рыцарьларына каршы, яулап алучы булырга теләгән Карл XII нчегә каршы, император Наполеонның бөек армиясенә каршы көрәшкән кешеләрнең турылыклы варисын котлыйбыз.

Үз ватаның, иң хыянәтчел һәм шәфкатьсез басып алучыдан, көнбатыш культурасына коточкыч куркыныч килүдән саклап батырларча һәлак булган кешеләрне без котлыйбыз һәм алар турында кайгырабыз.

Сталинград, Ростов, Харьков янындагы җиңүләр алар өчен үч алырлар. Без аларның сугыш батырлыкларын котлыйбыз. Без алга, киләчәктәге җиңүләргә, безнең тарафтан яулап алыначак соңгы җиңүгә омтылабыз.

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность, транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ 1055 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 282